**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Экспорт советын оештыру турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Экспорт советын оештыру турында» 2018 елның 21 апрелендәге ПУ-326 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 29 декабрендәге ПУ-1003 номерлы һәм 2022 елның 13 декабрендәге ПУ-871 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Экспорт советы турында нигезләмәдә:

4.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы Экспорт советы (алга таба – Совет) составында:

Совет составыннан А.Т. Әйделдиновны, В.С. Гинсбургны, Е.Н. Подшиваловны, М.Н. Садыйковны чыгарырга;

Совет составына кертергә:

Галиев Дамир Рәсил улын – «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директорын (килешү буенча);

Генкель Роман Александровичны – «Россия экспорт үзәге» акционер җәмгыятенең финанс булмаган продуктларны, төбәк һәм чит ил челтәрләрен үстерү һәм партнерлык сәясәте буенча вице-президентын (килешү буенча);

Зайцев Андрей Сергеевичны – «Россия экспорт үзәге» акционер җәмгыятенең төбәк бизнесын үстерү буенча директорын (килешү буенча);

Миңнуллин Марсель Мансур улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Яковлев Николай Юрьевичны – «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча);

Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Н. Миңнехановның – «Татарстан Республикасы Рәисе, Совет рәисе»;

Ф.С. Абдулганиевның – «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе»;

Г.Т. Бакировның – «Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе»;

Е.Ф. Рапопортның – ««Инкомсистем» фәнни-инженерлык үзәге» ябык акционер җәмгыяте генераль директорының өлкән киңәшчесе»;

С.В. Соловьевның – «ДжиДиСи Сервисез» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының корпоратив идарә буенча киңәшчесе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 29 декабрь
№ 919